РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.10.2019 № 705

**Тәтеш муниципаль районы белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогия хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр бирү тәртибен раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Педагогия хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр бирү турындагы” 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карары нигезендә, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР ИТТЕ:**

1. Тәтеш муниципаль районы белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогия хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр бирү тәртибен расларга.

2. “Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе начальнигы Т.В. Красулинага Тәтеш муниципаль районы белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә җиткерергә.

3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны “Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе начальнигы Т.В. Красулинага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Б. Семенычев**

Тәтеш муниципаль районы
башкарма комитетының
2019 елның 10 октябрендәге
705 номерлы карарына кушымта

**Тәтеш муниципаль районы белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогия хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр бирү тәртибе**

1. Әлеге тәртип Тәтеш муниципаль районы белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогия хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр бирү күләмен һәм тәртибен билгели.

2. Педагогия хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләрне финанслау әлеге тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларда тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган акчалар исәбеннән башкарыла.

3. Педагогия хезмәткәре - яшь белгеч - һөнәри белем бирү оешмасын яки югары белем бирү программалары - бакалавриат, специалитет, магистратура (алга таба һөнәри белем бирү оешмасы яки югары белем бирү оешмасы) буенча дәүләт аккредитациясе булган югары уку йортын көндезге формада тәмамлаган, һөнәри белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе буенча 1 ноябрьдән дә соңга калмыйча хезмәт килешүе буенча оешмага эшкә кабул ителгән 30 яшькә кадәр зат.

4. Ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр педагогия хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә эшкә урнашу датасыннан алып педагогик вазыйфада өзлексез өч ел эшләү дәверендә билгеләнә.

Педагогия хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләрне билгеләү, туктату, озайту турындагы карар учреждение боерыгы белән раслана.

Педагогия хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр вакыты озайтыла:

хезмәт итү;

йөклелек һәм бала табу, 3 яшькә кадәр бала карау буенча ял;

көндезге формада аспирантурада уку очракларында.

Ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр педагогия хезмәткәре - яшь белгеч Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә чакырылыш хезмәте яисә альтернатив граждан хезмәте тәмамланганнан соң 60 көннән дә соңга калмыйча хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштерсә, йөклелек һәм бала табу буенча ял, балага өч яшь тулганчы карау буенча ял алган очракта саклана.

Аспирантурада белем алганнан соң, педагогия хезмәткәрләре - яшь белгеч югары белем бирү оешмасын тәмамлаганнан соң елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштерергә тиеш.

5. Ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр алу өчен әлеге тәртипнең 3 нче пунктында билгеләнгән эшкә урнашу вакытын үтәмәүнең җитди сәбәпләре булып документаль рәвештә расланган вакытлыча эшсезлек тора. Педагогия хезмәткәрләре - яшь белгеч вакытлыча эшсезлек тәмамланган көннән соң 60 көннән дә соңга калмыйча рәсмиләштерсә, ай саен стимуллаштыручы өстәмә акча түләнә.

6. Педагогик хезмәткәр - яшь белгечне башка муниципаль районга күчергәндә, педагогик вазыйфага башка оешмага күчкәндә 30 көннән дә артмаган эш вакытыннан тукталып тору рөхсәт ителә.

7. Педагогик хезмәткәр - яшь белгечне эштән чыгарганда, алга таба педагогик юнәлешле эшкә урнашканда, эштәге тәнәфес 30 көннән дә артык булмаска тиеш.

8. Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләү хокукы бирә торган оешмаларның төрләре:

мәктәпкәчә белем бирү оешмалары;

гомуми белем бирү оешмалары;

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар;

өстәмә белем бирү оешмалары.

9. Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен бирелә торган өстәмә түләү төп педагогик вазыйфа буенча билгеләнә.

10. Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү бары тик төп эш урыны буенча гына билгеләнә.

11. Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү укыту күләменең ни дәрәҗәдә булуына карап билгеләнә, әмма аена 1111 сумнан да артык түгел.

Яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү белем бирү буенча төп педагогик вазыйфа һәм педагогик хезмәт буенча билгеләнә.

12. Хезмәт хакы ставкасы өчен атнасына (елга) педагогик эш сәгатьләре нормалары билгеләнгән педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = P \times H_f / H_n,$$

D - педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә хезмәт хакы ставкасы өчен атнасына (елга) педагогик эш сәгатьләре нормалары билгеләнгән, әмма 1111 сумнан да артмаган өстәмә айлык түләү күләме;

P - педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә атнасына (елга) педагогик эш сәгате нормасы өчен 1111 сум күләмендә стимуллаштыручы өстәмә түләү;

Hf - педагогик эш алып бару сәгатьләренең факттагы саны;

$H_n$ - хезмәт хакының база ставкасы өчен сәгать нормасы.

13. Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә (ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр әлеге тәртипнең 12 пункты белән билгеләнгән педагогик хезмәткәрләр - яшь белгечләрдән тыш) ай саен стимуллаштырыла торган өстәмә түләү түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = P \times t,$$

D - педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме, әмма аена 1111 сумнан да артмый;

P - педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә өстәмә түләү хезмәт хакы ставкасы өчен 1111 сум;

t - фактта эшләнгән вакыт (ставкалар).

14. Педагогик хезмәткәрләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләр исәбеннән түләнә.

15. “Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы мәгариф бүлеге” МКУ ел саен агымдагы елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәге документларны тапшыра:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү өчен акча бирү турында гариза;

ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү өчен акча бирү турында гариза бирүче затның вәкаләтләрен раслаучы документ;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыклары белән расланган форма буенча педагогик хезмәткәрләр - учреждениенең яшь белгечләре реестры.